Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче
Түбән Суык-Су авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

« 14 » апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче Түбән Суык-Су авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү(балалар мәйданчыгы өчен балалар уены элементларын сатып алу, күпфатирлы йортлар территориясен төзекләндерү, ташуга каршы чаралар (траншеялар урнаштыру, туфрак өеме, агачлар кисү);

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Түбән Суык-Су авылында урамнарны яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) урнаштыру, сатып алу);

- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, ремонт эшләре));

- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү (сугышчыны буяу, яңарту));

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (күлне камышлардан чистарту);

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын инвентарен сатып алу һәм урнаштыру (гидрант, көпшә, җиңсә))».

2) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү(балалар мәйданчыгы өчен балалар уены элементларын сатып алу, күпфатирлы йортлар территориясен төзекләндерү, ташуга каршы чаралар (траншеялар урнаштыру, туфрак өеме, агачлар кисү);

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Түбән Суык-Су авылында урамнарны яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) урнаштыру, сатып алу);

- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, ремонт эшләре));

- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү (бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү (сугышчыны буяу, яңарту));

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (күлне камышлардан чистарту);

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын инвентарен сатып алу һәм урнаштыру (гидрант, көпшә, җиңсә))».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Түбән Суык-Су авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Д.З.Фазуллин